КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 октябрь г.Казань № 1257

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел,

31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 4 июль, 549 нчы; 2019 ел, 29 март, 239 нчы; 2019 ел, 13 сентябрь, 830 нчы; 2020 ел, 12 май, 380 нче; 2020 ел, 11 ноябрь, 1011 нче; 2020 ел, 3 декабрь, 1090 нчы; 2021 ел, 21 июль, 626 нчы; 2021 ел, 29 октябрь, 1019 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1325 нче; 2022 ел, 4 апрель, 312 нче; 2022 ел, 21 июнь, 593 нче; 2022 ел, 20 октябрь, 1123 нче; 2022 ел, 1 декабрь, 1273 нче; 2022 ел, 16 декабрь, 1348 нче; 2023 ел, 13 июнь, 712 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның 4 бүлегенә  түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру» дәүләт программасын һәм муниципаль программаларны үтәү барышы турында, шул исәптән әлеге программалар кысаларында иҗтимагый һәм ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча конкрет чараларны гамәлгә ашыру барышы турында гражданнарга мәгълүмат бирү тәртибе Программаның $5^1$ нче кушымтасында китерелде.»;

Программага $5^1$ нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин